# КАРАР

**2022 елның 17 ноябре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Яңа Комар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 17 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Ошторма-Юмья авыл җирлеге Яңа Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Яңа Комар авылының Урман, Яшьләр урамы юлларына вак таш җәю , ремонтлау (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Яңа Комар авылында янгын гидрантлары, янгын рукавлары, стволлар, переходниклар, колонкалар, мотопомпа сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәләгә ашыру;
- су белән тәэмин итү системаларын төзекләндерү, ремонтлау (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Яңа Комар авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

2022 елның 17 ноябренә торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны – 127 кеше.

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 105 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 55.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 55 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Яңа Комар авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Ошторма-Юмья авыл җирлеге Яңа Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1250 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Яңа Комар авылының Урман, Яшьләр урамы юлларына вак таш җәю , ремонтлау (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Яңа Комар авылында янгын гидрантлары, янгын рукавлары, стволлар, переходниклар, колонкалар, мотопомпа сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәләгә ашыру;

- су белән тәэмин итү системаларын төзекләндерү, ремонтлау (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Яңа Комар авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- видеокүзәтү системасы сатып алу һәм урнаштыру (видеокамера, видеорегистратор, коммутатор, каты диск, монитор сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Осторма-Юмья авыл җирлеге башлыгы С.В. Тимофеев